**9 сыйныф өчен дәрестән тыш эшчәнлеккә аннотация**

“Туган телем-татар теле” дәрестән тыш эшчәнлек Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

- Россия Федерациясенең "Мәгариф турында"гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ "Об образовании в Российской Федерации").

- Татарстан Республикасының "Мәгариф турында"гы Законы (Закон Республики Татарстан "Об образовании" № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8).

- Россия Федерациясенең "Россия Федерациясе халыктелләре турында"гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998).

-Зур Мәшләк урта гомуми белем бирү мәктәбенең төп гомуми белем бирү программасы (2018 елның 16 августында №120 номерлы боерык белән расланган)

-Зур Мәшләк урта гомуми белем бирү мәктәбенең 2020-2021 уку елы өчен еллык календарь графигы 20.08.2020 елның № 99 о/д номерлы боерык белән расланган.

**Максат:**

“Татар теле- матур тел” өстәмә дәресеноештыруның төп максаты - сәләтле балаларны барлау, аларның иҗади сәләтен үстерүгә шартлар тудыру, укучыларда халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре, дине, татар халкының язучылары, шагыйрьләре, драматурглары, артистлары, гомумән, күренекле шәхесләрен өйрәнү аркылы туган телгә һәм халкыбызга мәхәббәт һәм ихтирам хисләре тәрбияләү.

**Бурычлар:**

Әлеге максатка ирешү юлында татар укучыларына әдәбият фәне буенча түгәрәк үткәрүнең төп бурычлары түбәндәгечә билгеләнә:

1. Укучының татар әдәби телен үзләштерүенә, текстны аңлап, сәнгатьле итеп, төрле темаларга иркен сөйләшүенә ирешү, тел һәм әдәбият буенча иҗади сәләтен үстерү һәм иҗат итәргә омтылыш тудыру.
2. Балаларны мәктәп программасында булмаган, Балык Бистәсендә яшәп иҗат итүче, халык арасында яратып укыла торган язучыларның аерым вәкилләре һәм аларның иҗат үрнәкләре белән таныштыру..
3. Авылыбыз, районыбыз язучыларының иҗатын өйрәнү аша авыл, район тарихы, аның күренекле кешеләре, традицияләре белән танышу.
4. Тормышларын әдәбият дөньясына, журналистикага багышлаган укучыларны киләчәктә мөстәкыйль белем алуга, алган белемнәренә нигезленеп, укуларын югары уку йортларында уңышлы дәвам итәрлек укучылар хәзерләү.